Хокук саклау органнары хезмәт-кәрләре булып кvренгән телефон мошенниклары Саранск пенсионерын аларга 207 мен сум акча кvчерергә кvндергәннәр.
70 яшьлек зыян кvрvченен сvзләренчә, башта алдакчылар аны полиция хезмәткәрләре, аннары ФСБ хезмәткәрләре дип таныштырган. Әнгәмәдәшләр мошен-никларнын анын исеменә кредит рәсмиләштергәннәрен хәбәр итә. Шул ук вакытта алар бу факт турында беркемгә дә сойләмәvне әйтәләр.   Рохсәтсез гамәлләрне булдырмас очен кредит картасы счетындагы акчаларны алу һәм аларны диктантланган реквизитлар буенча кvчерv таләп ителә. Шуннан сон билгесез кешеләр хатын-кызга башка банкка барырга такси чакырталар, анда аларнын кvрсәтмәсе буенча 150 меннән артык суммадагы кредит рәсмиләштерелә.
Алган акчаларны да пенсионер хатын жинаятьчеләргә кvчерә. Әмма мошенниклар кабат анын кредитын рәсмиләштерvен таләп итә. Ләкин финанс учреждениесе кредитны хуп-лаудан баш тарта. Мошенниклар корбаны булуын анлап, полициягә морәжәгать итә. Хәзерге вакытта жинаять кылуда катнашы булган кешеләр билгеләнә.
Мондый шалтыратулар кергәндә Мордовия Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы гражданнарга сойләшvне туктатырга һәм шәхсән банкка морәжәгать итәргә кинәш итә.